Гөсел алу әдәпләре

آداب الغسل

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM

الغسل : هو تعميم البدن بماء طهور على وجه مخصوص بشروط وأركان.

Гөсел – ул билгеле булган тәртиптә тәнне чиста су белән юешләтү. Аның шартлары һәм нигезләре бар.

- ومن الغسل ما هو واجب كغسل الجنابة والحيض.

ومنه ما هو سنة كغسل العيدين.

Гөсел ике төрле була: фарыз һәм сөннәт гөселләре. Якынлык кылганнан соң һәм хатын-кызларның күреме беткәннән соң алына торган гөсел фарыз гөселеннән булып тора. Ураза гәетендә һәм корбан гәетендә алынган гөсел сөннәт гөселләреннән булып тора.

وللغسل آداب منها :

Гөсел алуның әдәпләре бар, һәм шулардан:

- الخلوة والاستتار بعيداً عن الأنظار.

– Башка кешеләр тәненңне күрми торган урында гөсел алу.

فعن يَعلى أنّ رسول الله صلى الله عليه وسلم رأى رجلا يغتسل بالبراز أي بالفضاء الواسع بلا ازار فصعد المنبر فحمد الله وأثنى عليه ثم قال: إن الله عز وجل حيي ستير يحب الحياء والستر؛ فإذا اغتسل أحدكم فليستتر.

Ягъләдән хәбәр ителә: "Бервакыт Пәйгамбәребез ﷺ ачык урында, тәнен кешеләрдән яшермичә гөсел алган кешене күрә. Аның өстендә хәтта изары да булмый. Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ минбарга менеп басып Аллаһны мактый да, әйтә: "Чынлыкта, Аллаһ Оялчан, һәм Яшерен, һәм Ул оялчанлыкны һәм яшертенлекне ярата. Әгәр берәрегез гөсел ала икән, яшеренсен".

ومن آداب الغسل تجنب الإسراف في استعمال الماء أو صبه بلا حاجة

– Шулай ук гөсел алу әдәпләреннән – суны исраф итеп кирәксезгә агызудан саклану.

فإن النبي صلى الله عليه وسلم قال :
انه سيكون في هذه الأمة قوم يعتدون في الطهور

Пәйгамбәребез ﷺ: "Шушы өммәттә чиста суны исраф итүче кавем булыр",- дип хәбәр итте.

وقد أجمع العلماء على النهي عن الإسراف في الماء ولو في شاطئ البحر

Хәтта кеше дингез буенда булса да, галимнәребез бер сүздән суны исраф кылу тыелган дип әйттеләр.

- ومن آداب الغسل أن يبدأ بالوضوء وأن يحرص على اسباغ الغسل وذلك بتبليغ الماء جميع البدن وإيصاله إلى معاطف الجسم ومنابت الشعر.

– Шулай ук гөсел алу әдәпләреннән – гөселне тәһарәттән башлап, суны бөтен тәненә, хәтта чәч арасына тидереп, яхшылап, тулысынча, җиренә җиткереп алу.

فعن أم المؤمنين عائشة رضي الله عنها قالت : كان رسول الله صلى عليه وسلم إذا اغتسل من الجنابة غسل يديه ثم توضأ وضوءه للصلاة ثم يخلل رأسه بأصابعه حتى إذا خيّل إليه أنه قد استبرأ البشرة غرف على رأسه ثلاثا ثم غسل سائر جسده.

Гаишәдән (аннан Аллаһ разый булсын) хәбәр ителә: "Пәйгамбәребез ﷺ хатыны белән якынлык кылганнан соң гөсел алганда иң беренче ике кулын юа торган булган. Аннан соң намазга алган сыман тәһарәт алган. Шуннан соң баш тиресенең юешлеген тойганчыга кадәр бармаклары белән чәч арасын тәрәшләп башына өч тапкыр су салган һәм шуннан соң тәненең калган өлешләрен юа торган булган".